**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1374**
**04.03.2024**

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8503 номерлы Карары белән расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8503 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 25 апрелендәге 3367 номерлы Карары редакциясендә) расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5 пунктның унынчы абзацында «ЕГИССО – социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «ЕЦП – Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2.6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1) бала туу турында мәгълүматлар – ГХАТ БДР;

2) язылышу (аерылышу) турында мәгълүматлар – ГХАТ БДР;

3) ата булуны билгеләү турында мәгълүматлар – ГХАТ БДР;

4) опека һәм попечительлек органы карарыннан балага опека билгеләү турында мәгълүматлар – Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлеге;

5) яшәү (тору) урыны турында мәгълүматлар – Россия ЭЭМ;

6) баланың тулысынча дәүләт тәэминатында булуы турында мәгълүматлар – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

7) фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәртү турында мәгълүматлар – ГХАТ БДР;

8) ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында мәгълүматлар – ЕЦП;

9) ата-ана хокукларын чикләү турында мәгълүматлар – ЕЦП;

10) баланы алу турында мәгълүматлар – ЕЦП;

11) инвалид турында мәгълүматлар өземтәсе – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды;

12) хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә хезмәткәрнең һәлак булуы (үлүе), хәбәрсез югалган дип тану турында мәгълүматлар – Россия Федерациясе Оборона министрлыгы;

13) датага билгеләнгән пенсияләр һәм социаль түләүләр турында белешмә – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды;

14) күп балалы гаилә статусы булу турында мәгълүматлар – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

15) Россия Федерациясе гражданының гамәлдәге паспорты турында мәгълүматлар – Россия ЭЭМ;

16) нотариаль ышаныч язуы турында мәгълүматлар – Федераль нотариаль палата.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов